ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 декабрь, 2021 ел № 11/5

Шәһәр Советының «Даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче затларның хезмәтенә түләү системасы турында» 2018 елның 27 апрелендәге 24/6 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контрольисәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы карары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче затларның хезмәтенә түләү системасы турында» 2018 елның 27 апрелендәге 24/6 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/14, 2020 елның 23 сентябрендәге 1/12, 2021 елның 3 ноябрендәге 9/4 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 8.1-8.2 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасарына айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, өстәмә айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнергә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга

мөмкин. Шул ук вакытта аларның акчалата түләүләренең айлык җыелма күләме Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата түләүләрнең 0,8 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.

8.2. Контроль-хисап палатасы аудиторларына айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, өстәмә айлык акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнергә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр дә башкарылырга мөмкин. Шул ук вакытта аларның акчалата түләүләренең айлык җыелма күләме Контроль-хисап палатасы рәисенә акчалата түләүләрнең 0,6 айлык җыелма күләменнән артмаска тиеш.»;

2) 15 пунктның 3 пунктчасындагы икенче – өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәтнең элек биләгән вазыйфалары белән чагыштырганда югарырак төркеменә караган вазыйфасына билгеләнгән очракта, ул били торган вазыйфага караган вазыйфалар төркеме өчен беренче классны чин биргәнгә кадәр классны чин өчен аның оклад күләмен исәпләп чыгару вазыйфаи окладның 3 процентына тигез булган процент ставкасыннан чыгып башкарыла.

Әгәр дә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәтнең элек биләгән вазыйфалары белән чагыштырганда түбәнрәк төркеменә караган вазыйфасына билгеләнсә һәм элек биләгән вазыйфасы буенча аңа классны чин бирелсә, классны чин өчен оклад күләмен исәпләп чыгару вазыйфаи окладның 7 процентына тигез булган процент ставкасыннан чыгып башкарыла;».

2. Әлеге Карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Контроль-хисап палатасы Рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ